ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка дәүләт теркәү билгеләре булмаган, танылмый торган, стандарт булмаган яисә дәүләт стандарты таләпләрен бозып урнаштырылган номерлы транспорт чараларын куюны (аларның туктап торуын) тыю мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка дәүләт теркәү билгеләре булмаган, танылмый торган, стандарт булмаган яисә дәүләт стандарты таләпләрен бозып урнаштырылган номерлы транспорт чараларын куюны (аларның туктап торуын) тыю мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының күрсәтелгән мөрәҗәгатен хуплауны сорап, Россия Федерациясе субъектлары закон чыгару (вәкиллекле) органнарына мөрәҗәгать итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2019 елның 14 феврале
№ 2725-V ДС

**Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка дәүләт теркәү билгеләре булмаган, танылмый торган, стандарт булмаган яисә дәүләт стандарты таләпләрен бозып урнаштырылган номерлы транспорт чараларын куюны (аларның туктап торуын) тыю мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате**

Хөрмәтле Дмитрий Анатольевич!

Казан шәһәре транспорт комплексының нәтиҗәле эшләвен арттыру буенча соңгы елларда күрелә торган чаралар, шул исәптән бердәм парковка урыннары системасын булдыру, шәһәр үзәгендә транспорт чараларының теләсә ничек куелуын киметергә, аларны озак вакытка калдырып китү шартларын чикләргә, урамнарның үткәрә алуын 18% ка һәм шәһәрнең төп магистраль урамнарында транспортның хәрәкәт итү тизлеген 5 км/сәг кә арттырырга мөмкинлек бирде.

Моның белән бергә хәзерге вакытта гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан түләүле парковкаларда дәүләт теркәү номерлары алып куелган яисә чит предметлар белән ябылган автомобильләрне парковкаларга кую белән бәйле проблема кискен тора.

Хәзерге вакытта федераль законнарда күрсәтелгән юл кишәрлекләрендә номерлары алып куелган яисә танылмый торган транспорт чараларын куюны (аларның туктап торуын) тыю каралмаган һәм шуңа күрә административ җәза да юк. Автомобиль йөртүчеләр, моны белеп, күрсәтелгән гамәлләрне башкаралар. Нәтиҗәдә автомобиль кую урынын эзләүгә күбрәк вакыт сарыф ителә, законнарга тугры йөртүчеләргә кыенлыклар туа, алар моңа ризасызлык белдерә.

Югарыда күрсәтелгән проблема күп кешене борчый, шуңа күрә ул Россия Федерациясенең барлык субъектлары өчен дә актуаль.

Әлеге мәсьәләне хәл итү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларына (шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Юл хәрәкәте кагыйдәләре турында” 1993 елның 23 октябрендәге 1090 номерлы карарына) автомобиль юлының бер өлеше булып торган һәм (яисә) йөрү юлына һәм (яисә) тротуарга, юл кырыена, эстакадага яки күпергә тоташкан йә эстакада асты яки күпер асты җирләренең, мәйданнарының һәм башка урам-юл объектларының бер өлешен тәшкил иткән дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдә урнашкан түләүле парковкаларда дәүләт теркәү билгеләре булмаган, танылмый торган, стандарт булмаган яисә дәүләт стандарты таләпләрен бозып урнаштырылган номерлы транспорт чараларын куюны

(аларның туктап торуын) тыюны кертә торган, шул ук вакытта тиешле административ җәза төрен билгеләп, үзгәреш кертергә тәкъдим итәбез.

Әлеге үзгәрешләр зур шәһәрләрдәге урамнарның транспорт агымын үткәрә алу сәләтен шактый арттырырга, шулай ук төп магистраль урамнар буенча транспортның хәрәкәт итү тизлеген дә арттырырга мөмкинлек бирәчәк.